«Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» проекты буенча 2024 елның 16 ноябрендәге гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар

НӘТИҖӘСЕ

«Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» проекты буенча фикер алышканнан соң, гавами тыңлауларда катнашучылар тәкъдим ителгән проектның «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, РФ Җир кодексы, РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә әзерләнгәнлеген билгеләп үттеләр. Башка өстәмәләр һәм үзгәрешләр килмәде.

«Җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү турында» проект буенча чыгышларны тыңлаганнан соң, гавами тыңлауларда катнашучылар бертавыштан карар чыгардылар:

1. «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» проекты буенча гавами тыңлауларны узган дип исәпләргә.
2. «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» проектны тәкъдим ителгән документлар нигезендә хупларга.
3. ТР Кукмара муниципаль районының Янил авыл җирлеге башлыгы И.Х.Корбановка «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында» проектны килештерергә һәм «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә раслау өчен Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына җибәрергә киңәш итәргә.
4. Гавами тыңлаулар буенча йомгакны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Рәислек итүче И.Х.Корбанов